КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 18 октябрь г.Казань № 840

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешләрендә өстәмә белем бирү оешмаларын һәм өстәмә белем бирүче күпюнәлешле оешмаларны финанслау нормативларын хисаплап чыгару тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2009 ел, 31 декабрь, 939 нчы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешләрендә өстәмә белем бирү оешмаларын һәм өстәмә белем бирүче күпюнәлешле оешмаларны финанслау нормативларын хисаплап чыгару тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2009 ел, 31 декабрь, 939 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 3 сентябрь, 701 нче, 2012 ел, 13 февраль, 111 нче, 2022 ел, 4 июль, 621 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «финанслау нормативлары» сүзләрен «норматив чыгымнар» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «финанслау нормативлары» сүзләрен «норматив чыгымнар» сүзләренә алмаштырырга;

2 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

3 пунктта «финанслау нормативлары» сүзләрен «норматив чыгымнар» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта:

икенче абзац үз көчен югалткан дип танырга;

дүртенче абзацта «финанслау нормативлары» сүзләрен «норматив чыгымнар» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «финанс чыгымнары нормативлары» сүзләрен «норматив чыгымнар» сүзләренә, «мәгариф оешмаларында милекне тоту нормативлары» сүзләрен «оешмаларның милекне тоту (эксплуатацияләү) норматив чыгымнары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешләрендә өстәмә белем бирү оешмаларын һәм өстәмә белем бирүче күпюнәлешле оешмаларны финанслау нормативларын хисаплап чыгару тәртибе турындагы нигезләмәдә:

исемендә «финанслау нормативлары» сүзләрен «норматив чыгымнар» сүзләренә алмаштырырга;

1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасының балаларга туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешләрендә өстәмә белем бирү оешмаларында һәм өстәмә белем бирүче күпюнәлешле оешмаларда өстәмә гомумүстерү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнарны, өстәмә белем бирү оешмалары мөлкәтен тотуга (эксплуатацияләүгә) һәм өстәмә белем бирүне оештыруны финанс белән тәэмин итү күләменә норматив чыгымнарны исәпләп чыгару тәртибен билгели .»;

1.2 пунктта «Финанс чыгымнары нормативлары» сүзләрен «Норматив чыгымнар» сүзләренә, «белем бирү» сүзләрен «гомумүстерү» сүзенә, «(алга таба – финанс чыгымнары нормативы)» сүзләрен «(алга таба – өстәмә гомумүстерү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнар)» сүзләренә алмаштырырга;

1.3 пунктта «Карап тоту нормативы» сүзләрен «Карап тотуга (эксплуатациягә) норматив чыгымнар» сүзләренә, «(алга таба – мөлкәтне карап тоту нормативы)» сүзләрен «(алга таба – мөлкәтне карап тотуга (эксплуатациягә) норматив чыгымнар» сүзләренә, «белем бирү» сүзләрен «гомумүстерү» сүзенә алмаштырырга;

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Өстәмә гомумүстерү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнар һәм мөлкәтне тотуга (эксплуатацияләүгә) норматив чыгымнар Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда кулланыла һәм чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан ел саен раслана. «;

1.5 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

1.6 пунктта:

«финанс чыгымнары нормативы һәм мөлкәтне тоту нормативы» сүзләрен «өстәмә гомумүстерү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнар һәм мөлкәтне тотуга (эксплуатацияләүгә) норматив чыгымнар» сүзләренә алмаштырырга;

«һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр бюджетлары» сүзләрен өстәргә;

1.7 пунктта «Финанс чыгымнары нормативы билгеләнә» сүзләрен «Өстәмә гомумүстерү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнар билгеләнә» сүзләренә алмаштырырга;

1.8 пунктта «Финанс чыгымнары нормасы билгеләнә» сүзләрен «Өстәмә гомумүстерү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнар билгеләнә» сүзләренә, «милекне карап тоту нормативы билгеләнә» сүзләрен «милекне карап тоту (эксплуатацияләү) чыгымнары нормативы билгеләнә» сүзләренә алмаштырырга;

1.9 пунктта «финанс чыгымнары нормативлары һәм мөлкәтне тоту нормативлары» сүзләрен «өстәмә гомумүстерү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнар һәм мөлкәтне тотуга (эксплуатацияләүгә) норматив чыгымнар» сүзләренә алмаштырырга;

1.01 пунктның беренче абзацында «белем бирү» сүзләрен «гомумүстерү» сүзенә алмаштырырга;

1.11 пунктның беренче абзацында «белем бирү» сүзләрен «гомумүстерү» сүзенә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 1.12 пункт өстәргә:

1.12. Законнар нигезендә өстәмә белем бирү оешмаларында сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән, инвалид укучылар өчен медицина нәтиҗәсе нигезендә инклюзив белем бирүне оештыру юлы белән төркемнәр оештырганда өстәмә гомумүстерү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнар елга бер укучыга билгеләнә.»;

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә гомумүстерү программаларын гамәлгә ашыру чыгымнары нормативын исәпләү тәртибе

2.1. Өстәмә белем бирү оешмаларында өстәмә гомумүстерү программаларын гамәлгә ашыру чыгымнарына өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә чыгымнар, дәреслекләргә һәм уку пособиеләренә, укытуның техник чараларына, чыгым материалларына һәм хуҗалык ихтыяҗларына чыгымнар керә (биналарны карап тоту һәм коммуналь чыгымнардан тыш).

2.2. Өстәмә гомумүстерү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнар бер укучыга исәпләп, түбәндәгеләр нигезендә билгеләнә:

педагогик хезмәт күрсәтүнең стандарт (база) бәясе;

педагогик хезмәткәрләрнең хезмәт хакы ставкалары һәм административ-идарә һәм уку-ярдәмче персоналның хезмәт хакы ставкаларының норматив нисбәте;

белем бирү процессы һәм административ-идарә персоналы эшчәнлеген тәэмин итү чыгымнары.

2.3. Педагогик хезмәт күрсәтүнең стандарт (база) бәясен исәпләү өстәмә гомумүстерү программасының юнәлеше һәм тәренә, уку дәрәҗәсенә карап, бер укучыга башкарыла, түбәндәге күрсәткечләрдән чыгып:

беренче уку елы өчен атнага бер укучыга 0,27 сәгать, икенче уку елы өчен 0,5 сәгать, өченче һәм аннан соңгы уку еллары өчен 0,6 сәгать педагогик сәгатьләр саны;

педагогик хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләүгә чыгымнар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 412 нче карары нигезендә билгеләнә.https://login.consultant.ru/link/?req=doc&base=RLAW363&n=190282&date=04.06.2025

2.4. Белем бирү процессын һәм административ-идарә персоналы эшчәнлеген тәэмин итү чыгымнары күрсәтмә әсбаплар, укыту чаралары, мәгълүмати-коммуникатив чаралар, экран-тавыш әсбаплары, уку-тәҗрибә җиһазлары, уку-методик әдәбият, чыгым материаллары, канцелярия товарлары сатып алу чыгымнарын, шулай ук командировка чыгымнарын һәм педагогик хезмәткәрләргә методик әдәбият сатып алу өчен компенсация түләүләрен үз эченә ала (алга таба – белем бирү процессын һәм административ-идарә персоналы эшчәнлеген тәэмин итү чыгымнары).

2.5. Өстәмә гомумүстерү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнар () бер укучыга исәпләп, түбәндәге формула буенча исәпләнә$N_{sp}^{t}$:

$$N_{sp}^{t} = FOT_{sp}^{t} + MTO_{sp},$$

монда:

$FOT_{sp}^{t}$ – педагогик, административ-идарә һәм уку-ярдәмче персоналның хезмәт хакын түләү фондына исәпләүләр белән педагогик, административ-идарә һәм уку-ярдәмче персоналның хезмәт хакын түләү фонды;

$MTO_{sp}$ – белем бирү процессы һәм административ-идарә персоналы эшчәнлеген тәэмин итү чыгымнары;

s – балаларның өстәмә гомумүстерү программасының төре (юнәлеше);

p – уку вакыты;

t – өстәмә белем бирү оешмасының территориаль урнашуы (шәһәр, авыл җирлеге).

2.6. Федагогик, административ-идарә һәм уку-ярдәмче персоналның хезмәт хакын түләү фондына исәпләүләр белән педагогик, административ-идарә һәм уку-ярдәмче персоналның хезмәт хакын түләү фонды () түбәндәге формула буенча исәпләнә:$FOT_{sp}^{t}$

$$FOT_{sp}^{t} = FOT_{sp_{пс}}^{t} + FOT_{sp_{ауп}}^{t},$$

монда:

$FOT_{sp_{пс}}^{t}$ – педагогик персоналның хезмәт хакы фондына исәпләүләр белән педагогик персоналның хезмәт хакы фонды;

$FOT_{sp_{ауп}}^{t}$ – административ-идарә һәм уку-ярдәмче персоналның хезмәт хакын түләү фондына исәпләүләр белән административ-идарә һәм уку-ярдәмче персоналның хезмәт хакын түләү фонды;

s – балаларның өстәмә гомумүстерү программасының төре (юнәлеше);

p – уку вакыты;

t – өстәмә белем бирү оешмасының территориаль урнашуы (шәһәр, авыл җирлеге).

2.7. Педагогик персоналның хезмәт хакы фондына исәпләүләр белән педагогик персоналның хезмәт хакы фонды () түбәндәге формула буенча исәпләнә:$FOT^{t}_{sp_{пс}}$

$$FOT^{t}_{sp_{пс}} = \frac{a_{sp_{пс}}}{z} \times O_{T} \times (1 + e) \times 12,$$

монда:

$a_{sp_{пс}}$ – балаларны өстәмә гомумүстерү программасының юнәлеше һәм төренә, әлеге Нигезләмәнең 2.3 пунктына ярашлы рәвештә укыту дәрәҗәсенә бәйле рәвештә бер укучыга атналык педагогик сәгатьләр саны.

z– Россия Федерациясенең Мәгариф министрлыгының «Төп һәм өстәмә гомуми белем бирү программалары, урта һөнәри белем бирү уку-укыту программалары һәм тиешле һөнәри белем бирү программалары, төп һөнәри белем бирү программалары, һөнәри белем бирүнең төп программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның педагог хезмәткәрләренә эш вакытының (хезмәт хакы ставкасы өчен педагогик эш сәгатьләре нормалары) дәвамлылыгы турында һәм хезмәт килешүендә әйтелә торган күрсәтелгән педагогик хезмәткәрләрнең укыту йөкләнешен билгеләү тәртибе, аны үзгәртү нигезләре һәм әлеге уку-укыту йөкләнешенең югары чиге билгеләнгән очраклар турында» 2025 елның 4 апрелендәге 269 номерлы боерыгы нигезендә педагогларның хезмәт хакы ставкасы өчен сәгатьләр саны;

$O_{T}$ - хезмәт өчен түләүгә чыгымнар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 412 нче карары нигезендә билгеләнә;

e - хезмәт өчен түләү буенча түләүләргә исәпләүләр ставкасы;

12 – бер елда айлар саны;

s – балаларның өстәмә гомумүстерү программасының төре (юнәлеше);

p – уку вакыты;

t – өстәмә белем бирү оешмасының территориаль урнашуы (шәһәр, авыл җирлеге).

2.8. Административ-идарә һәм уку-ярдәмче персоналның хезмәт хакын түләү фондына исәпләүләр белән административ-идарә һәм уку-ярдәмче персоналның хезмәт хакын түләү фонды () түбәндәге формула буенча исәпләнә:$FOT^{t}_{sp_{ауп}}$

$$FOT^{t}_{sp_{ауп}} = FOT^{t}_{sp_{пс}} \times K_{ауп},$$

монда:

$FOT^{t}_{sp_{пс}}$ – педагогик персоналның хезмәт хакы фондына исәпләүләр белән педагогик персоналның хезмәт хакы фонды;

$K_{ауп}$– административ-идарә һәм уку-ярдәмче ярдәмче персоналның хезмәт хакына чыгымнар өлеше педагогик персоналның хезмәт хакы фондыннан 14 процент тәшкил итә;

s – балаларның өстәмә гомумүстерү программасының төре (юнәлеше);

p – уку вакыты;

t – өстәмә белем бирү оешмасының территориаль урнашуы (шәһәр, авыл җирлеге).

2.9. Белем бирү процессын тәэмин итү һәм административ-идарә персоналы эшчәнлегенә чыгымнар ө$MTO_{sp}$стәмә гомүстерү программасының төренә (юнәлешенә) карап 1 нче таблица буенча билгеләнә.

1 нче таблица

Белем бирү процессы һәм административ-идарә персоналы эшчәнлеген тәэмин итү чыгымнары

| Т/с | Өстәмә гомумүстерү программасының төре (юнәлеше) | Белем бирү процессын тәэмин итүгә чыгымнар, елга сум |
|---|---|---|
| 1. | Техник иҗат | 900 |
| 2. | Сәнгать-эстетик | 500 |
| 3. | Физкультура-спорт | 400 |
| 4. | Туристик-туган якны өйрәнү | 500 |
| 5. | Экология-биология | 500 |
| 6. | Хәрби-патриотик | 500 |
| 7. | Социаль-педагогик | 300 |
| 8. | Социаль-икътисадый | 300 |
| 9. | Табигый-фәнни | 500 |

2.10. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән, инвалидлыгы булган укучылар өчен өстәмә белем бирү оешмаларында инклюзив белем бирүне оештыру юлы белән өстәмә гомумүстерү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнар бер укучыга түбәндәге формула буенча исәпләнә:$N^t_{sp_{ovz}}$

$$N^t_{sp_{ovz}} = N^t_{sp} + FOT^t_{sp_{ovz}} + MTO_{sp_{ovz}},$$

монда:

$N^t_{sp}$ - өстәмә гомуми үстерү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнар;

$FOT^t_{sp_{ovz}}$ – инклюзив белем бирүне оештыручы персоналның хезмәт хакы фонды;

$MTO_{sp_{ovz}}$ – сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән, инвалидлыгы булган укучылар өчен белем бирү процессын тәэмин итү чыгымнары;

s – балаларның өстәмә гомумүстерү программасының төре (юнәлеше);

p – уку вакыты;

t – өстәмә белем бирү оешмасының территориаль урнашуы (шәһәр, авыл җирлеге).

Инклюзив белем бирүне оештыручы персоналның хезмәт хакы фонды ($FOT^{t}_{sp_{ovz}}$) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$FOT^{t}_{sp_{ovz}} = \frac{a_{sp_{ovz}}}{z_{ovz}} \times O_{T} \times (1 + e) \times 12,$$

монда:

$a_{sp_{ovz}}$ – сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән, инвалидлыгы булган бер укучыга уку вакытының атналык сәгатьләре: терәк-хәрәкәт аппараты бозылган, психик үсешләрендә тоткарлыклар булган, аутистик спектры тайпылышлары булган һәм үсешнең күп санлы бозулары булган укучылар өчен укытуның беренче елы өчен 0,67 сәгать күләмендә, укытуның икенче елы өчен 1,0 сәгать, укытуның өченче һәм аннан соңгы еллары өчен 1,0 сәгать күләмендә; ишетү сәләте бозылган укучылар: чукраклар, начар ишетүчеләр, соң ишетүчеләр өчен укытуның беренче елы өчен 0,33 сәгать күләмендә, укытуның икенче елы өчен 0,5 сәгать, өченче һәм аннан соңгы еллар өчен 0,5 сәгать күләмендә;

$z_{ovz}$ – инклюзив белем бирүне оештыруны гамәлгә ашыручы персоналның хезмәт хакы ставкасы өчен сәгатьләр саны: терәк-хәрәкәт аппараты бозылган, психик үсешләрендә тоткарлык булган, аутистик спектр тайпылышлары булган һәм үсешнең күп санлы бозулары булган укучыларны озатып йөрүче педагог персонал өчен - Россия Федерациясенең Мәгариф министрлыгының «Төп һәм өстәмә гомуми белем бирү программалары, урта һөнәри белем бирү уку-укыту программалары һәм тиешле һөнәри белем бирү программалары, төп һөнәри белем бирү программалары, һөнәри белем бирүнең төп программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның педагог хезмәткәрләренә эш вакытының (хезмәт хакы ставкасы өчен педагогик эш сәгатьләре нормалары) дәвамлылыгы турында һәм хезмәт килешүендә әйтелә торган күрсәтелгән педагогик хезмәткәрләрнең укыту йөкләнешен билгеләү тәртибе, аны үзгәртү нигезләре һәм әлеге уку-укыту йөкләнешенең югары чиге билгеләнгән очраклар турында» 2025 елның 4 апрелендәге 269 номерлы боерыгы нигезендә ишетү сәләте бозылган чукрак, начар ишетүче, соң ишетүче укучыларны озатып йөрүче «сурдотәрҗемәче» вазыйфасы өчен - атнага 40 сәгать;

$O_{T}$ - хезмәт өчен түләүгә чыгымнар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 412 нче карары нигезендә билгеләнә;

e - хезмәт өчен түләү буенча түләүләргә исәпләүләр ставкасы;

12 – бер елда айлар саны;

s – балаларның өстәмә гомумүстерү программасының төре (юнәлеше);

p – уку вакыты;

t – өстәмә белем бирү оешмасының территориаль урнашуы (шәһәр, авыл җирлеге).

Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән, инвалидлык булган укучылар өчен белем бирү процессын тәэмин итүгә өстәмә чыгымнар $еМТО_{sp_{ovz}}$лга 140 сум күләмендә билгеләнә.»;

3 бүлектә:

исемендә «карап тоту нормативы» сүзләрен «карап тотуга (эксплуатацияләүгә) норматив чыгымнар» сүзләре белән алмаштырырга;

3.1 пунктның беренче абзацында «карап тоту» сүзләрен «карап тоту (эксплуатацияләү)» сүзләренә алмаштырырга;

3.2 пунктның беренче абзацында «Карап тотуның база нормативы» сүзләрен «Карап тотуга (эксплуатацияләүгә) база норматив чыгымнар» сүзләренә алмаштырырга;

3.10 пунктта:

беренче абзацта «Карап тотуның база нормативы» сүзләрен «Карап тотуга (эксплуатацияләүгә) база норматив чыгымнар» сүзләренә алмаштырырга; «исәпләнә» сүзен «исәпләнәләр» сүзенә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «карап тотуның база нормативы» сүзләрен «карап тотуга (эксплуатацияләүгә) база норматив чыгымнар» сүзләренә алмаштырырга;

3.16 пунктта:

беренче абзацта «карап тотуның база нормативына» сүзләрен «карап тотуга (эксплуатацияләүгә) база норматив чыгымнарга» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «карап тотуның база нормативына» сүзләрен «карап тотуга (эксплуатацияләүгә) база норматив чыгымнарга» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «карап тоту нормативы» сүзләрен «карап тотуга (эксплуатацияләүгә) норматив чыгымнар» сүзләренә алмаштырырга;

3.17 пунктның беренче абзацында «Карап тоту нормативы» сүзләрен «Карап тотуга (эксплуатацияләүгә) норматив чыгымнар» сүзләренә алмаштырырга;

3.18 пунктның беренче абзацында «Карап тотун нормативы» сүзләрен «Карап тотуга (эксплуатацияләүгә)норматив чыгымнар» сүзләренә алмаштырырга;

4.1 пунктта:

икенче абзацта «белем бирү» сүзләрен «гомумүстерү» сүзенә алмаштырырга;

өченче абзацта «карап тоту» сүзләрен «карап тоту (эксплуатацияләү)» сүзләренә алмаштырырга;

4.2 пунктның бишенче абзацында «финанслау нормативлары» сүзләрен «норматив чыгымнар» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин